КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 сентябрь г.Казань № 782

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчегә һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эш белән мәшгуль булмаган гражданнарга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 28 февраль, 128 нче карары белән расланган Эш бирүчегә һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эш белән мәшгуль булмаган гражданнарга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчегә һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эш белән мәшгуль булмаган гражданнарга хезмәт

өчен түләү чыгымнарының бер өлешен кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 28 февраль, 128 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1135 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Эш бирүчегә һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эш белән мәшгуль булмаган гражданнарга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта «2014 – 2020 елларга» сүзләрен «2014 – 2025 елларга» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бетерү, үзгәртеп оештыру процессында булмау, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, аларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмау – юридик затлар өчен, индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмау – индивидуаль эшмәкәр өчен;»;

6 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып эш бирүченең заявкасында күрсәтелгән һәм субсидия бирү чоры дәвамында эш бирүче тарафыннан сакланган эш урыннары саны тора.»;

икенче абзацта «Нәтиҗәлелек күрсәткече» сүзләрен «Нәтиҗә күрсәткече (R)» сүзләренә алыштырырга;

бишенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

7 нче пунктта:

беренче абзацта «Субсидия күләме» сүзләрен «Субсидия күләме (S)» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Субсидия алу өчен эш бирүчеләр, агымдагы елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча, үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру урыны буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә түбәндәгеләрне тапшыра:

бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча заявка;

эш бирүченең җитәкчесе (индивидуаль эшмәкәр) һәм баш бухгалтеры яки бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи затының имзасы куелган, эш бирүченең мөһере (мөһере булганда) белән расланган субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау турында белешмә кәгазен (ирекле формада);

эш бирүченең җитәкчесе (индивидуаль эшмәкәр) һәм баш бухгалтеры яки бухгалтерлык исәбен алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи затының имзасы куелган, эш бирүченең мөһере (мөһере булганда) белән расланган эш бирүченең бу

Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын раслый торган белешмә кәгазен;

эш бирүченең җитәкчесенең имзасы куелган һәм эш бирүченең мөһере (мөһере булганда) белән расланган эш бирүченең үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, юридик затларга карата – аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын, индивидуаль эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктатмавын раслый торган белешмә кәгазен.

8.1. Эш бирүче үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә гариза белән мөрәҗәгать иткәнгә кадәр өч айдан да иртәрәк булмаган вакыт эчендә бирелгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә) күчермәсен;

салым органында исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсен;

салым органының салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау турындагы белешмә кәгазен;

Эш бирүче тарафыннан бу пунктның икенче – дүртенче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.»;

10 нчы пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш бирүче тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 8 нче пунктында каралган таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);»;

13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Шартнамәдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидияне күчерү тәртибе, субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе, өстәмә хисаплылык бирү вакытлары һәм формасы (кирәк булганда), эш бирүче тарафыннан субсидияне кире кайтару очраклары, тәртибе, вакытлары, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан эш бирүченең субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерү, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан эш бирүченең субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыру, эш бирүченең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан эш бирүченең субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыруга ризалыгы, эш бирүченең бу Тәртип шартларын һәм төзелә торган шартнамәне үтәве турында нигезләмәләр, килешүнең шартларын бозган өчен

җаваплылык, эш бирүченең һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең бу Тәртиптә каралган башка шартлары һәм бурычлары карала.

Кирәк булганда, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге һәм эш бирүче Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча шартнамәгә өстәмә килешү, шул исәптән шартнамәне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидияне күчерү халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан ай саен, субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бу Тәртипнең 10 пунктындагы беренче абзацында билгеләнгән вакытта эш бирүченең Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисапны эш бирүче ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10ысыннан да соңга калмыйча, бу Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшыра.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка аның тарафыннан расланган формалар буенча Татарстан Республикасы бюджетының башкарылган чыгымнары турында һәм эш бирүче тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшыра.

Министрлыкка тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә йөкләнә.»;

17 нче пунктта:

беренче һәм икенче абзацларда тиешле килешләрдәге һәм саннардагы «субсидия алучы» сүзләрен тиешле килешләрдәге һәм саннардагы «эш бирүче» сүзләренә алыштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«нәтиҗә күрсәткеченә ирешмәгән очракта, шартнамә белән күздә тотылган нәтиҗә күрсәткеченең ирешелмәгән мәгънәсе өчен субсидия суммасыннан бер процент күләмендә.»;

18 нче пунктның икенче җөмләсендә «субсидия алучы» сүзләрен «эш бирүче» сүзләренә алыштырырга;

19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан эш бирүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.»;

Тәртипкә теркәлгән кушымтаның башисемендә «кушымта» сүзен «1 нче кушымта» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Эш бирүчегә һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эш белән мәшгуль булмаган гражданнарга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 3 сентябрь, 782 нче
карары редакциясендә)

Форма

________________________________________________________________
Эш бирүченең исеме

эш бирүчегә һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эш белән мәшгуль булмаган гражданнарга хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен кайтаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисабы

| Т/с | Нәтиҗәнең исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификациясе буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсен үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1. | Эш бирүченең заявкасында күрсәтелгән һәм субсидия бирү чоры дәвамында эш бирүче тарафыннан саклanган эш урыннары саны | Эш урыны | 904 | | | | |

____________________ (җитәкченең вазыйфасы)

____________________ (җитәкче, индивидуаль эшмәкәр имзасы, Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда))

М.У.*

Баш бухгалтер ____________ (имзасы) ____________ (имзаны таркатып язу)

20__ ел, «___» ___________

* Мөһер булганда.

______________________________